БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«08» ноябрь 2021 ел № 345

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү системасында авария хәлләре килеп чыкканда (барлыкка килү куркынычы булганда) кулланучыларның җылылык энергиясен куллану режимнарын авария хәлендә чикләү һәм җылылык энергиясен бирүне чикләү, туктату графиклары турында нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясын, «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2013 елның 27 июлендәге 190 номерлы Россия Федерациясе Федераль законының 20 статьясын, «Россия Федерациясендә җылылык белән тәэмин итүне оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 8 августындагы 808 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарын, Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 2013 елның 12 мартындагы 103 номерлы боерыгы белән расланган Җылылык бирү чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләрен гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү системасында авария хәлләре килеп чыкканда (барлыкка килү куркынычы булганда) кулланучыларның җылылык энергиясен куллану режимнарын авария хәлендә чикләүне һәм җылылык энергиясен бирүне чикләүне, туктатуны вакытында һәм оешкан төстә максатларында, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү системасында авария хәлләре килеп чыкканда (барлыкка килү куркынычы булганда) кулланучыларның җылылык энергиясен куллану режимнарын авария хәлендә чикләү һәм җылылык энергиясен бирүне чикләү, туктату графиклары турында нигезләмәне расларга (кушымта).

2. Җылылык белән тәэмин итүче оешмалар җитәкчеләренә әлеге Нигезләмәгә таянып эшләүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда

бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов

Балтач район башкарма комитетының
2021 елның 08.11
345 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү системасында авария хәлләре килеп чыкканда (барлыкка килү куркынычы булганда) кулланучыларның җылылык энергиясен куллану режимнарын авария хәлендә чикләү һәм җылылык энергиясен бирүне чикләү, туктату графиклары турында**

# НИГЕЗЛӘМӘ

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1.Җылылык белән тәэмин итү системасында авария хәлләре килеп чыкканда (барлыкка килү куркынычы булганда) кулланучыларның җылылык энергиясен куллану режимнарын авария хәлендә чикләү һәм җылылык энергиясен бирүне чикләү, туктату графиклары (алга таба - графиклар) һәр җылылык чыганагы буенча аерым төзелә (тутыру үрнәге - 1 нче таблица).

1.2. Графиклар ел саен төзелә һәм энергосистемада ягулык, җылылык энергиясе һәм куәте кытлыгы барлыкка килгәндә, табигый бәла-казалар (яшен, бура, су басу, янгын, озак торган салкыннар һ.б.) очрагында, кулланучы тарафыннан шартнамәдә билгеләнгән вакытта җылылык энергиясе өчен түләү документын түләмәгән очракта, аварияләр барлыкка килүне һәм артуны булдырмас өчен, аларны бетерү өчен һәм кулланучыларның тәртипсез тукталурын булдырмау өчен кертелә.

1.3. Графиклар Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе белән килештереп, җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан эшләнә һәм гамәлгә кертелә.

1.4. Кулланучыларны челтәрдәге суда җылылык җибәрү буенча чикләү турыдан-туры челтәрдәге су температурасын киметү юлы белән яки челтәрдәге су циркуляциясен чикләү юлы белән котельныйда үзәкләштереп башкарыла.

1.5. Кулланучыларның җылылык энергиясен куллану режимнарын авария хәлендә чикләү графигы котельныйларда яки җылылык челтәрләрендә авария барлыкка килү куркынычы янаганда яисә авария барлыкка килгәндә, кулланучыларга җылылык энергиясен бирүне чикләү графигын кертү өчен вакыт җитмәгәндә кулланыла. Кулланучыларга җылылык энергиясе бирүне туктату чираты котельныйларны һәм җылылык челтәрләрен эксплуатацияләү шартларыннан чыгып билгеләнә.

1.6. Әлеге Нигезләмә һәм расланган график нигезендә, кулланучылар, субабонентларны исәпкә алып, предприятиене чикләүнең һәм авария хәлендә өзүнең индивидуаль графикларын төзиләр.

## 2.Графиклар төзүгә гомуми таләпләр

2.1. Графиклар җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан ел саен эшләнә һәм агымдагы елның 1 ноябреннән киләсе елның 1 ноябренә кадәр гамәлдә була.

Эшләнгән график Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан килештерелә һәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан алар расланганнан соң 10 көн эчендә кулланучыларга язмача җиткерелә.

2.2. Җылылык энергиясен һәм куәтен кулланучыларны чикләүнең һәм авария хәлендә өзүнең күләмен һәм чиратлылыгын билгеләгәндә, график кертүдән килгән зыян минималь булсын өчен объектның дәүләт, хуҗалык, социаль әһәмияте һәм кулланучының җитештерүенең технологик үзенчәлекләре исәпкә алынырга тиеш.

Шулай ук кулланучыларның җылылык белән тәэмин итү схемасының үзенчәлекләре һәм җылылык энергиясен һәм куәтен кулланучыларны чикләүләрне һәм авария хәлендә өзүләрне үтәүне нәтиҗәле контрольдә тотуны тәэмин итү мөмкинлеге дә исәпкә алынырга тиеш.

2.3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә графикка 2 нче кушымта нигезендә объектлар кертелми.

2.4.Графикка кертелгән кулланучылар белән берлектә җылылык белән тәэмин итүне авария һәм технологик броньлауның ике яклы актлары төзелә (3 нче кушымта). Авария һәм технологик броньның йөкләнеше аерым билгеләнә.

## 3. Җылылык белән тәэмин итүнең авария броне

Кешеләрнең тормышын, җиһазларның, технологик чималның, продукциянең һәм янгын куркынычсызлыгы чараларының сакланышын тәэмин итүче иң аз кулланыла торган җылылык куәте яки җылылык энергиясе чыгымы.

3.1 Җитештерү күләмен, технологик процессны үзгәртүгә яисә җылылык белән тәэмин итү схемасына бәйле булган кулланучыларда җылылык белән тәэмин итүнең авария броне күләмен үзгәрткәндә, актларны яңадан карау гариза кергән көннән бер ай эчендә кулланучылар гаризасы буенча башкарыла. Бу ай дәвамында, кулланучыларны чикләүләр һәм өзүләр керткәндә, җылылык белән тәэмин итү элек төзелгән технологик һәм авария броне актлары нигезендә, ә чикләүләр кертү - элек эшләнгән графиклар буенча башкарыла.

Авария һәм технологик бронь күләме үзгәргәндә, графикларга үзгәреш кертелә һәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан кулланучыларга һәм котельный җитәкчелегенә язмача хәбәр ителә.

3.2 Кулланучы җылылык белән тәэмин итүнең авария һәм технологик броне актын төзүдән язмача баш тарткан очракта, бер ай эчендә гамәлдәге норматив документлар һәм әлеге Нигезләмә нигезендә, кулланучыга 10 көн эчендә язмача хәбәр итеп, кулланучының җылылык җайланмалары җылылык

энергиясен һәм куәтен чикләү һәм авария хәлендә туктату графикларына кертелә.

Бу очракта җылылык энергиясен һәм куәтен куллануны чикләү һәм өзү нәтиҗәләре өчен кулланучы җавап тота.

3.3. Графикларга искәрмәдә чикләүләр һәм туктатулар кагылмаган кулланучылар исемлеге күрсәтелә.

## 4. Җылылык энергиясен һәм куәтен кулланучыларны чикләү графикларын кертү тәртибе

4.1. Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе белән килештереп, җылылык энергиясен кулланучыларны чикләү графиклары җылылык белән тәэмин итүче оешманың диспетчерлык хезмәтләре (булганда) яки вазыйфаи затлары (алга таба – Вазыйфаи зат) аша кертелә. Җылылык белән тәэмин итүче оешма җитәкчесе боерыгы белән билгеләнгән вазыйфаи зат, чикләүләр күләмен, башлану һәм тәмамлану вакытын күрсәтеп, котельный җитәкчесенә йөкләмәне җиткерә.

4.2. Вазыйфаи зат һәркем файналана ала торган элемтә каналлары буенча җылылык энергиясен кулланучыга графикларны гамәлгә ашыра башлаганчы 12 сәгатьтән дә соңга калмыйча, чикләүләр күләмен, башлану һәм тәмамлану вакытын күрсәтеп, графикларны кертү турында хәбәр итә.

## 5. Җылылык куәтен кулланучыларны авария хәлендә өзү графикларын кертү тәртибе

5.1. Котельныйда яисә җылылык челтәрләрендә кинәт авария хәле барлыкка килгән очракта, алга таба Вазыйфаи зат тарафыннан 2 сәгать эчендә өзү сәбәпләре турында кулланучыга җиткерү шарты белән, җылылык энергиясен кулланучыларны кичекмәстән өзәләр.

5.2. Котельныйның, җылылык челтәрләре участокларының төп җиһазларының озак (авария) вакытка сафтан чыккан очракта, җылылык энергиясен кулланучыларны өзү графигы шул ук күләмгә чикләүләр графигы белән алмаштырыла.

5.3. Кулланучыларны чикләүләр һәм өзүләр кертү факты һәм сәбәпләре турында, җылылык энергиясен җибәреп бетермәү күләме турында, график кертелгән вакытта килеп чыккан булса, аварияләр турында авыл җирлекләре башкарма комитеты җитәкчесенә һәмТатарстан Республикасы Балтач муниципаль районы БДДХнең кизү (дежур) торучысына билгеләнгән тәртиптә җиткерелә.

## 6. Җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның бурычлары, хокуклары һәм җаваплылыгы

6.1. Җылылык белән тәэмин итүче оешма кулланучыларга җылылык энергиясен һәм куәтен чикләүгә йөкләмәләрне һәм чикләүләрнең гамәлдә

булу вакытын җиткерергә тиеш. Кулланучылар тарафыннан графикларны үтәүне контрольдә тотуны җылылык белән тәэмин итүче оешма гамәлгә ашыра.

6.2. Җылылык белән тәэмин итүче оешма билгеләнгән вакытка бирелгән күләмнәр турында хәбәр итәргә һәм графикларны кертү турында күрсәтмәләрнең үтәлешен тәэмин итәргә бурычлы һәм гамәлдәге законнар нигезендә, графикларны гамәлгә кертү буенча күрсәтмәләрне тиз һәм төгәл үтәү өчен җаваплы.

6.3. Җылылык белән тәэмин итүче оешма җитәкчесе графикларны кертүнең нигезле булуы, чикләүләрне кертү күләме һәм вакытлары өчен җаваплы.

6.4. Графикларны нигезсез керткәндә, җылылык белән тәэмин итүче оешма законнарда каралган тәртиптә җавап тота.

## 7. Җылылык энергиясен кулланучыларның бурычлары, хокуклары һәм җаваплылыгы

Кулланучылар (предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр җитәкчеләре) җылылык энергиясен һәм куәтен авария хәлендә чикләүләр һәм өзүләр графикларын берсүзсез үтәү өчен, шулай ук аларны үтәмәүгә бәйле нәтиҗәләр өчен җаваплы.

Кулланучы бурычлы:

7.1. Җылылык белән тәэмин итүче оешмалардан җылылык энергиясен һәм куәтен чикләүләр һәм авария хәлендә өзүләр графикларын кертү турында хәбәрләрне тәүлек вакытына карамастан кабул итүне тәэмин итәргә;

7.2. Җылылык энергиясен һәм куәтен чикләүләр һәм авария хәлендә өзүләр графикларын керткәндә законлы таләпләрнең ткичектергесез үтәлешен тәэмин итәргә;

7.3. Тәүлекнең теләсә кайсы вакытында җылылык белән тәэмин итүче оешма вәкилләрен җылылык энергиясен һәм куәтен куллануны чикләүнең һәм өзүнең бирелгән күләмнәренең үтәлешен контрольдә тоту өчен барлык җылылык кулланучы җайланмаларга тоткарлыксыз кертергә;

7.4. Ике яклы акт нигезендә, авария һәм технологик бронь йөкләнешен аерып күрсәтеп, җылылык белән тәэмин итү схемасын тәэмин итәргә.

Кулланучы җылылык белән тәэмин итүче оешмага чикләүләр күләме һәм вакыты өлешендә чикләү графиклары кертү нигезсез булу турында гариза белән язмача мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль
районы территориясендә җылылык белән тәэмин
итү системасында авария хәлләре килеп чыкканда
(барлыкка килү куркынычы булганда)
кулланучыларның җылылык энергиясен куллану
режимнарын авария хәлендә чикләү һәм җылылык
энергиясен бирүне чикләү, туктату графиклары
турында Нигезләмәгә
1 нче кушымта

**көзге-кышкы чорда җылылык белән тәэмин итү системасы буенча җылылык куәте яки ягулык җитмәгәндә, җылылык энергиясен кулланучыларны чикләү һәм авария хәлендә өзү**

**ГРАФИГЫ**

| Җылылык чыганагы кулланучы | Шартнамәдә күрсәтелгән рөхсәт ителгән иң чик күрсәткеч | Тәүлеклек файдалы җибәрү күләме | Авария броне | Технологик бронь | Чират номеры һәм төшерелә торган йөкләнеш зурлыгы | оператив персоналның, кулланучының, чикләүләр кертү өчен җаваплының Ф. И. А., вазыйфасы, телефоны |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Балтач штп | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Татарстан Республикасы Балтач
муниципаль районы территориясендә
җылылык белән тәэмин итү системасында
авария хәлләре килеп чыкканда (барлыкка
килү куркынычы булганда)
кулланучыларның җылылык энергиясен
куллану режимнарын авария хәлендә
чикләү һәм җылылык энергиясен бирүне
чикләү, туктату графиклары турында
Нигезләмәгә
2 нче кушымта

**Җылылык энергиясен һәм куәтен вакытлыча өзү графигына кертелмәгән җылылык энергиясен (аерым объектларны) кулланучылар исемлеге.**

1. Оборона Министрлыгы объектларында:

- хәрби частьләрнең шәхси составының тәүлек буе эшләве каралган;

- тәүлек буе хәрби кизү (дежур) торуны тәэмин итү каралган;

2. Социаль өлкәнең муниципаль объектлары: мәктәпкәчә учреждениеләр, гомуми белем бирү мәктәбе

3. Милек рәвешләренә карамастан, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан медицина учреждениеләре.

4. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан Россия Федераль куркынычсызлык хезмәтенең, Россия Эчке эшләр министрлыгының, Россия ГТХМның объектлары.

Татарстан Республикасы Балтач
муниципаль районы территориясендә
жылылык белән тәэмин итү системасында
авария хәлләре килеп чыкканда (барлыкка
килү куркынычы булганда)
кулланучыларның жылылык энергиясен
куллану режимнарын авария хәлендә
чикләү һәм жылылык энергиясен бирүне
чикләү, туктату графиклары турында
Нигезләмәгә
3 нче кушымта

## Жылылык белән тәэмин итүне авария һәм технологик броньлау актлары

1. Предприятиенең исеме
2. Адресы
3. Телефоннары: житәкченең
4. Шартнамә йөкләнеше - , Гкал/с
5. Предприятиенең алмашлыгы -
6. Ял көннәре -
7. Технологик бронь зурлыгы -
8. Авария броне зурлыгы -
9. Тәүлеклек куллану - , Гкал/сәг

Әлеге актны төзеде

_______________________________________________
(дата) (вазыйфа, Ф.И.А.)

Предприятие вәкиле катнашында

_______________________________________________
(вазыйфасы Ф.И.А.)

| Жылылык чыганагы | Тәэмин итүче паропровод номеры | Технологик бронь | | | Авария броне | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Аларны өзү технологик процессны бозуга китерәчәк жылылык кабул итү жайланмалары исемлеге | Күләм, тн | Тәмамлау өчен кирәкле вакыт, сәгать | Аларны өзү шартлатуга, янгынга, чималны бозуга китерә торган, кешеләр тормышы өчен куркыныч тудыра торган | Авария броне зурлыгы, тн. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | жылылык кабул итү җайланмалары исемлеге | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Искәрмә: агымдагы елның 1 ноябреннән соң кулланучының җылылык белән тәэмин итү схемасында, җитештерү күләмендә үзгәрешләр килеп чыкса, акт кулланучы гаризасы буенча яңадан каралырга тиеш.

Актны төзеде: ______________________________
(Ф.И.А, вазыйфа)

Түбәндәгеләр катнашында: ______________________________
(Ф.И.А, вазыйфа)

Акт белән таныштылар: ______________________________
(Ф.И.А, вазыйфа)

Предприятие җитәкчесе ______________________________